# КАРДӘШЛӘР КОЧАГЫНДА

## СӘФӘР БИШТӘРЕ

Бу юлы мин сезне Төркия сәяхәтенә чакырам.

Берәр илгә юл тотканда, кирәк-ярак биштәрен әзерләү — барасы җир турында башлангыч мәгълүматларны өйдә туплау табигый. Кызык ич: ниндирәк ил ул Төркия? Кайда урнашкан, җире-суы, һавасы Татарстанныкыннан аерыламы? Халкы, аның гореф-гадәтләре, теле һәм мәдәнияте кайсы ягы белән илгизәрләр игътибарын тарта? Тарихы, хуҗалыгы, шәһәр-авыллары, төрле тармаклардагы казанышлары ничегрәк? Дөньяда тоткан урыны дәрәҗәлеме, безгә мөнәсәбәте, юллары һәм кунакханәләре яхшымы — сәяхәтче әнә шундый бик күп сорауларга җавап эзли. Гомуммәгълүматларны хәтердә яңарту — сәфәргә алдан әзерләнү ят ил белән танышуны әйбәтрәк оештырырга, үзең өчен иң тансыгын, иң кирәген күреп һәм белеп кайтырга, ялны күңеллерәк уздырырга булыша.

Мин Төркия турында дистәләгән китап укыдым. Совет галимнәре, язучылары бу илгә һич тә игътибар күрсәтмәгән дип әйтерлек түгел — фәнни тикшеренүләр дә, юлъязмалар да байтак нәшер ителгән. Ләкин аларның бер җитешсез ягы бар: Төркиягә марксизм, сыйнфый көрәш күзлегеннән карау. Тарихын исә Русия империясе мәнфәгатьләреннән чыгып яктырту. СССРның социалистик лагерьга кушу омтылышы аркасында, Төркия вакыйгаларының, казанышларының яхшы ук чалыш көзгедә чагылдырылуы, сафсаталар-саташулар, яла ягулар зур урын алуы бер дә гаҗәп түгел. Төрек язма чыганаклары, бигрәк тә төрек галимнәре хезмәтләре, хакыйкатьне дөрес күзаллатыр дип шикләндергәнгәме, элекке СССР халыклары телләренә аз тәрҗемә ителде. Шулай да алар бераз бар, тик ул басмаларга күпчелек укучының кулы җитмидер. Димәк, әүвәл Төркия турында кыскача белешмә бирү, мөгаен, акланыр.

**Мәйданы.** Төркия мәмләкәте Азия һәм Аурупа кыйтгаларында урнашкан. Аның йөздән өч өлешен Көнчыгыш Тракия (Аурупа), төп өлешен Анадулы (Ана дала), ягъни Кече Азия ярымутравы тәшкил итә. Тулай мәйданы

781 мең км$^2$, күрше илләр белән коры җир чиге 2753 чакрымга сузыла. Көнбатышта — Болгарстан белән Греция, төньяк-көнчыгышта — Грузия, Әрмәнстан һәм Азәрбайҗан, көнчыгышта — Иран, көньяк-көнчыгышта Гыйрак һәм Сүрия белән чикләнә. Аның төньягын — Кара диңгез, көнбатышын — Адалар (Эгей), көньягын Ак (Урта) диңгезләр юа.

Илнең Азия һәм Аурупа өлешләрен Мәрмәрә диңгезе һәм Кара диңгез (Босфор), Чанаккала (Дарданелл) бугазлары аерып тора. Кара диңгез бугазының көньяк ярларында дөньяның иң матур шәһәрләреннән берсе саналган Истанбул урнашкан. Бу каланың ике кыйтгага җәелгән өлешләре хәзер ике асма күпер белән тоташкан.

Мәрмәрә диңгезе һәм бугазлар аша чит ил кораблары узуы халыкара килешүләр буенча бара.

Төркия — таулы ил, аның көнчыгышындагы биек түбәләрдә мәңгелек кар ята. Биек тау сыртларының күпчелеге көнчыгыштан көнбатышка илнең буеннан-буена төньяк һәм көньяк чикләре буйлап сузыла һәм текә ярлары белән диңгезләргә килеп тоташа.

Анадулының уртасы — диңгез өстеннән бер-ике мең метр югарылыктагы тигез калкулык. Тау сыртлары арасында уңдырышлы үзәнлекләр күп, бозлыклардан агып төшкән елгалар җансыз чүлләрдә яшел оазислар барлыкка китергән. Тигез калкулыкларның бер өлеше шулай ук иген игәр өчен эшкәртелә.

Диңгез буйларында төньякта биш-ун чакрым киңлегендә, елга тамакларында тагын да киңрәк, хәтта йөз чакрымга җиткән пляж каймасы сузыла. Эгей диңгезе буендагы андый уңдырышлы иңкүлек каймасы тагын да киңрәк. Урта диңгез буендагы мәңге яшел Мәрсин — Адана түбәнлеге исә Төркиянең Флоридасы санала.

**Табигате.** Таулы ил булганлыктан, Төркиядә климатның барлык зоналары да очрый. Урта һәм Эгей диңгезләре буе субтропикларга керә, ягъни монда кышын да уртача җылылык нульдән түбән төшми. Мондый җылы кайма елга үзәнлекләре буенча ил эченә 300—400 чакрымгача сузыла. Бу каймага кояшлы җәй, яңгырлы җылы кыш хас.

Кара диңгез буе шулай ук чагыштырмача җылы, әмма монда дымлырак, кышын исә суыграк була. Ә менә эчке Анадулыда кыш озын һәм салкын, җәй коры һәм эссе, яз кыска һәм яңгырлы, көзе кыска, коры һәм җылы була. Күләме ягыннан Татарстаннан аерылмаса да, явым-төшем, нигездә, язын һәм кышын гына юмарт булганлыктан, иген игү мөмкинлекләрен шактый киметә.

Мәрмәрә диңгезе буена урнашкан Истанбулда җәй коры килә, кышын һәм көзен дымлы була. Гыйнвар, февраль айларында кар яуса да, җирне капламас борын эреп бетә. Ел әйләнәсенә монда яңгырлы 100 көн туры килә.

Төркия елгаларының барысы да диярлек таулардан башлана. Алар тар, кыска һәм сай сулы, юллары ташлы һәм бормалы, ярлары биек һәм текә. Көзен яки кышын ташыйлар, җәйләрен саегып яки тәмам кибеп бетәләр. Төркия чикләрендә озынлыгы зуррак елгалардан Фыратны (Евфрат — 1263 км), Кызыл Йырмакны (1182 км), Сакарьяны (824 км), Сәйханны (568 км), Дижләне (Тигр — 523 км) телгә алырга мөмкин. Илдәге зуррак күлләр исәбенә Ванны (өслеге — 3733 км$^2$), Тозны (1397 км$^2$), Бәйшәһәрне (650 км) кертергә була. Күлләрнең тулай мәйданы 9,2 мең км тәшкил итә.

Төркия җирләренең биштән дүрт өлешен ташлы балчык каплаган, алар игенчелек өчен өлешчә генә яраклы. Мондый җирләр, нигездә, көтүлек итеп файдаланыла, аларның бер өлешендә урманнар үсә. Урманнар илнең 23,4 процент мәйданын каплаган, ләкин аларның күпчелек өлеше куаклардан, тәбәнәк агачлардан гыйбарәт.

Уйсулыклар һәм тау итәкләре мәйданы чагыштырмача кечкенә булса да, хуҗалык өчен аларның әһәмияте зур. Гәдиз, Зур Мәндәрәс, Кече Мәндәрәс, Кызыл Йырмак һ. б. елгаларның үзәнлекләрендә, диңгез буендагы тигезлекләрдә көрән, кызгылт, коңгырт, көлсу туфраклар таралган. Кара туфрак Фракиядә һәм Төньяк-Көнчыгыш Анадулыда, Сакарья һәм Сусырлык елгалары үзәнлегендә очрый.

Төркия төрле климатик зоналарга урнашканлыктан, аның яшеллек дөньясы да бик бай — илдә 6500 төр үсемлек таралган. Тауларда ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, Кара диңгез буенда цитрус җимешләре, чәй һәм тәмәке, Урта, Эгей һәм Мәрмәрә диңгезләре буенда мәңге яшел агачлар тамыр җибәргән. Сәлви (кипарис), көмешсу чыршы, чинар, магнолия, дәфнә, зәйтүн, чикләвек, тау итәкләрендә йөзем, армут (груша), анар (гранат), шәфталу (персик) — ниләрне генә очратмыйсың монда. Адана — Мәрсин иңкүлеге җылы сөючән үсемлекләргә аеруча бай — мамык, дөге кырлары, банан, хөрмә, лимон, әфлисун, мандарин урманнары, тау битләрендә исә тут, анар, алма бакчалары җәелгән. Соңгы вакытта монда тропик илләрдән китерелгән җимешләр дә (мисалга, киви) үстерелә башлады. Анадулы калкулыкларында исә бездәгечә арпа, арыш, бодай, солы игелә. Дым җиткән җирләрдә монда да йөзем, кавын-карбыз үстерәләр.

Илнең уңдырышлы җирләрендә кайда да яшелчә, җиләк-җимеш җитештерү киң таралган. Ләкин моңа бер бәла комачаулый — су аз.

Төркиянең хайваннар дөньясы да бай. Кошлары һәм балыклары да төрле-төрле. Бу инде шулай ук аның җире-суы киңлегенә бәйләнгән.

Илнең казылма байлыклары әле тулысынча барланмаган. Хром, марганец, бакыр, кургашын, цинк мәгъдәннәре, мәрмәр, ташкүмер һәм бүтән чимал чыганаклары инде күптән үзләштерелгән, алардан чыгарылган хәзинәнең бер өлеше байтактан бирле чит илләргә дә сатыла.

**Халкы.** Төркия кеше саны буенча Якын һәм Урта Көнчыгышта беренче урында тора. Табигый артым 1990 елда 2,17 % тәшкил итте, бу — 1,3 миллион чамасы кеше дигән сүз. 1996 елда үсеш кимеде — 1,4 % чамасында булды, аның каруы гомер озынлыгы 1975—1996 елларда 60,3 яшьтән 67,3 кә күтәрелде. Соңгы дәвердә ил халкының саны һәм урнашу тыгызлыгы үсешен түбәндәге таблица күрсәтә:

| Елы | Халкы саны (мең) | 1 $км^2$ га туры килә |
|---|---|---|
| 1927 | 13 648 | 18 |
| 1935 | 16 158 | 21 |
| 1945 | 18 790 | 24 |
| 1955 | 24 065 | 31 |
| 1965 | 31 391 | 41 |
| 1975 | 40 348 | 52 |
| 1985 | 51 421 | 66 |
| 1990 | 57 163 | 73 |
| 1995 | 62 810 | 80 |
| 2000 | 66 600 | 85 |

Соңгы саннар эченә Көнбатыш Аурупада вакытлыча яшәүче өч миллион чамасы Төркия илдәше керми, күрәсең. Төркия халкының артуын (млн) АКШ һәм Русиянеке белән чагыштырып карыйк:

| Илләр | 1960 | 1980 | 2000 | 2020 | 2050 |
|---|---|---|---|---|---|
| АКШ | 180 | 227 | 274 | 323 | 394 |
| Русия | 119 | 139 | 145 | 141 | 121 |
| Төркия | 28 | 45 | 67 | 85 | 103 |

Халык ил буенча тигез генә урнашмаган. Мәрмәрә һәм Кара диңгез буйларында чагыштырмача тыгызрак тупланган. Анадулының үзәгенә һәм көнчыгышына ул сирәгрәк утырган. Шәһәр халкы 1985 елда беренче мәртәбә авылныкыннан артып китте һәм 1990 елда ил күләмендә 59 процент тәшкил итте. Димәк, Төркия авыл хуҗалыгы иленнән

сәнәгате үскән дәүләткә әверелеп килә. Шәһәрләшү илнең көнбатышында һәм үзәк төбәкләрендә тизрәк бара. Хәзер Истанбул (халкы 10 миллионнан артык), Әнкара (4 млн) һәм Измир (3 млн) дөнья күләмендә зур шәһәрләр исәбенә керә. Адана, Бурса калаларында да чама белән икешәр миллион кеше яши.

Милли яктан Төркия халкының 92 проценты — төрекләр. Алар Болгарстан, Греция, Кыбрыс, Гыйрак, Франция, Һолландия, Австралия, Бельгия, Англия, АКШ, Дания, Сүрия, Швеция, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һәм бүтән илләрдә дә яши. Алманиядә вакытлыча эшкә килгән 2 миллионнан артык Төркия илдәше бар. Төркия милли азчылыкларның төп өлешен исә көрдләр (6 млн чамасы) тәшкил итә, алар илнең көнчыгыш өлешендә һәм барлык зур шәһәрләрдә (4 млн) яши. Көньяк-көнчыгыш вилаятьләрдә берничә йөз мең гарәп бар. Чиркәс, грек, әрмән, грузин, лаз һәм бүтән азчылыкларның саны хәзер инде күп түгел — алар төрекләшә бара.

**Дине.** Төрекләр — дин ягыннан мөселман сөнниләр. Төркия — дөньяви ил, дин дәүләттән аерылган. Шулай да мөселманлык җәмгыять тормышында шактый зур йогынтыга ия. Ләкин азчылык милләтләрнең бүтән динне тотуларына да һичбер киртә куелмаган.

**Теле.** Төрек теле, түрк (бу атама барлык төрки халыкларны аңлата) телләре гаиләсенә кергәнлектән, грамматик төзелеше һәм сүзлек хәзинәсе белән татар теленә бик якын — тылмачсыз аңлашырлык хәлдә. Әмма ул азәри, төрекмән, гагауз телләренә тагын да якынрак һәм алар белән бергә түркләрнең угыз тармагын тәшкил итә. Әдәби төрек теле Истанбул шивәсе нигезендә барлыкка килгән.

Төрекләр озак дәвер рун һәм гарәп алфавитын кулланган, бары 1928 елда гына яңалифкә күчәргә карар биргән. Хәзерге төрек язуында 29 латин хәрефе һәм ике орфографик билге файдаланыла.

**Тарихы.** Аурупадагы тарих гыйлеме түрк халыкларының үткәнен «мәдәни» Кытай, Иран күләгәсендә калдырып, аларның казанышларын кечерәйтеп күрсәтергә яратканлыктан, түрк кабиләләренең Кече һәм Алгы Азиядә яшәвен дә XI йөздә генә башланган итеп расларга тырышты. Төркиянең үзендә дә төпле тарихи тикшеренүләргә XX йөздә генә нигез салыну аркасында, аның борынгы дәвере бик озак томан эчендә иде. Бу инде, әлбәттә, хәзерге Төркияне грек, грузин, көрд, әрмән халыкларының ата-бабалары җире дип игълан итү, төрекләрнең монда килмешәк кенә булуларын